РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.12.2017 № 1574-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 31 декабрендәге 1617-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары белән расланган дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары белән расланган дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 31 декабрендәге 1617-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә (алга таба - Тәртип):

**1.1.** Тәртипнең 23 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2015 елның 1 мартына гамәлдә булган һәм стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыруны күздә тоткан җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе

буенча үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәгән хуҗалык итүче субъект тарафыннан элек урнаштырылган стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру.;

Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру өчен җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе буенча төзелгән йөкләмәләрнең тиешенчә үтәлмәве шартнамә гамәлдә булган чорда аренда түләве (шул исәптән пеня) буенча бурыч, шулай ук стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру өчен килешү төзү турында гариза биргән вакытка җир кишәрлеген фактта файдалану буенча бурыч булып тора.

Бер урынга ике һәм аннан күбрәк заявка булган очракта, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә күрсәтелгән урынга сатулар үткәрмичә генә шартнамә төзүгә хокукы булган дәгъвачылар арасындагы сатулар нәтиҗәләре буенча төзелә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районының
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Р.М. Гасимов